ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 33 статьясына үзгәреш кертү хакында» 454-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 33 статьясына үзгәреш кертү хакында» 454-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 14 сентябре
№ 2126-VI ДС

Проект

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.Г. Хәбибуллин
тарафыннан кертелә

**Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 33 статьясына үзгәреш кертү хакында**

**1 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 33 статьясындагы 3 өлешенең 1 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы җыелма басмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш) «бүлекчәсе)» сүзеннән соң «яисә «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның $13^4$ статьясы нигезендә Россия Федерациясе Президенты Администрациясенең вәкаләтле бүлекчәсе» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 33 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

Закон проекты Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексын федераль законнардагы үзгәрешләргә туры китерү максатыннан эшләнде.

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 27.1 статьясында муниципаль хезмәткәрләргә карата әлеге Федераль законның аерым нигезләмәләрендә каралган җәзаларны куллану өчен нигезләр исемлеге бирелгән.

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 13 июнендәге 258-ФЗ номерлы Федераль закон белән әлеге исемлеккә Россия Федерациясе Президенты Администрациясенең вәкаләтле бүлекчәсе тарафыннан уздырылган тикшерү нәтиҗәләре турында доклад та өстәлгән.

Шуңа бәйле рәвештә Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына да шундый ук үзгәрешләрне кертергә кирәк.

**«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 33 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 33 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә яңаларын кабул итү таләп ителми.

**«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 33 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 33 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.